РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 15 сентябре № 36

Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама Советының 2010 елның 22 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

19 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «- муниципаль берәмлекләр чикләрендә урнашкан Ватанны саклаганда һәлак булганнарның җирләнгән урыннарын ачыклау.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары

М.В.Камелина